**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ**
**МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА АХМЕТОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ӘХМӘТ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Әхмәт ав. **КАРАР**

22 октябрь 2024 ел № 6

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законның 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ**:**

1. 2024 елның 8 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Нагорная урамында яшәүче гражданнар Җыенының беренче этабын уздыруны билгеләргә.

2. 2024 елның 8 ноябрендә 9 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Мәктәп, Заречная урамында яшәүче гражданнар Җыенының икенче этабын уздыруны билгеләргә.

3. 2024 елның 8 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Үзәк урамы, 51нче йорт адресы буенча урнашкан мәдәният йорты бинасында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Новая, Үзәк урамнарында яшәүче гражданнар Җыенының өченче этабын уздыруны билгеләргә.

4. 2024 елның 8 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Аксумла авылы, Ягодная урамы, 11нче йорт янында Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлегендәге Аксумла авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча Ягодная урамында яшәүче гражданнар Җыенының дүртенче этабын уздыруны билгеләргә.

5. Гражданнар җыенын уздыру өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген аерым бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.

6. Гражданнар җыены этапларын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Әхмәт авыл җирлеге башлыгы һәм Башкарма комитеты тарафыннан башкарыла.

7. Гражданнар җыенына чыгарылучы сорауны расларга:

«2025 елда Нурлат муниципаль районының Әхмәт авыл җирлеге Аксумла авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1нче төркем инвалидлардан, бачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала, һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм әлеге акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкару буенча мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- торак пунктлар территорияләрен төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ».

8. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Аксумла авылының мәгълүмат стендларында халык җыены этапларын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Әхмәт авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Лизратова